Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Исләй авылы җирлегенең Исләй авылы торак пунктында
гражданнар җыены

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Исләй авыл җирлеге составына керүче
Исләй авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре хакында
КАРАР

2019 елның 12 ноябре № 2

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль законның 25.1, 56 нчы маддәләре, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы Татарстан Республикасының 35 нче маддәсе нигезендә түбәндәге сорау буенча 2019 елның 12 ноябрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: "Чистай муниципаль районы Исләй авыл җирлегенең Исләй авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан тыш, I группа инвалидлардан тыш, 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- Исләй авылы эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту (вак таш сатып алу һәм ташу, грунтлау һәм акбурлау, вак таш салу, юлларны тигезләү, кар чистарту)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 160 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 128 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» тавышы өчен халык җыенында катнашкан 128 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Алда язылганнар нигезендә гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Чистай муниципаль районы Исләй авыл җирлегенең Исләй авылы торак пунктында гражданнар җыенын булды, гражданнар җыены нәтиҗәләре – гамәлдә дип танырга.

2. "Чистай муниципаль районы Исләй авыл җирлегенең Исләй авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм I группа инвалидларыннан тыш, 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- Исләй авылы эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту (вак таш сатып алу һәм ташу, грунтлау һәм акбурлау, вак таш салу, юлларны тигезләү, кар чистарту) буенча кабул ителде дип танырга.

3. Чистай муниципаль районы Исләй авыл җирлегенең Исләй авылы территориясендә Чистай муниципаль районы Исләй авыл җирлегенең Исләй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм I группа инвалидларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертергә, алынган

акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Исләй авылы эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту (вак таш сатып алу һәм ташу, грунтлау һәм акбурлау, вак таш салу, юлларны тигезләү, кар чистарту).

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм игъланнар такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга кирәк.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Исләй авыл җирлеге башлыгы _________________ В.П.Чернышев